ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 2 (I өлеш); 2010, № 3; 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары халык сәнгать һөнәрләренә һәм кәсепләренә (Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан исемлеге раслана торган халык сәнгать һөнәрләре оешмаларыннан тыш) ярдәм күрсәтә. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне эшләргә мөмкин:»;

2) түбәндәге эчтәлекле икенче өлеш өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан исемлеге раслана торган халык сәнгать һөнәрләре оешмаларына Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә ярдәм күрсәтергә хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 05 март
№ 7-ТРЗ